РӘҮФ ПӘҺЛЕВАН

# АВЫР ВАКЫТЛАРДА УКЫЛА ТОРГАН ДОГАЛАР

Шөкер, Аллаһтан мәрхәмәтен сорау,
теләк, стресс, курку, ихтыяҗ
һәм шифа догалары

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

www.daru ub.com

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

# КЕРЕШ СҮЗ

Дога чакыру, мөрәҗәгать итү, теләү, ярдәм сорау, исем кушу, ялвару, сыену дигән мәгънәләрне белдерә.

Догага мондый аңлатма бирергә мөмкин: «Дога, колның бөтен барлыгы белән Аллаһы Тәгаләгә юнәлеп, нәрсәнең дә булса үтәлүен яки үтәлмәвен сорап, Аңа мәдхия укып, көчсезлек вә ихтыяҗ белән теләктә булу».

www.darulkutub.com

Дога инсан белән Аллаһы Тәгалә арасында бер хәбәрләшү чарасы буларак та билгеләнә ала. Тыштан бу хәбәрләшү чарасы бер генә яклы кебек; фәкать догада гына аңлашыла торган бер юл белән Аллаһның җавап бирүенә ышаныч һәм өмет бар.

Вахи – Аллаһ белән инсан арасында барган югарыдан түбәнгә, ягъни Аллаһтан инсанга юнәлгән бер шәхси аралашу. Дога исә инсан белән Аллаһ арасында барган, түбәннән югарыга юнәлгән бер төр шәхси сөйләшү.

Дога инсанның Аллаһны чакыруы һәм Аңа сыенуы, Аллаһтан исә инсанга мәрхәмәт, бүләк һәм саклану чарасы буларак та аңлатыла ала.

Ислам буенча тормыш – Яралтучы белән яралтылган арасында бер элемтә булганга күрә, инсанның бөтен эшчәнлеге, үзе бу турыда уйламаса да, бер догадыр. Коръәндә бу болай аңлатыла: «догагыз булмаса, Раб-

www.darul-kutub.com

бы сезгә ни өчен игътибар бирсен?» («Фуркан» сүрәсенең 77 аяте).

Дога ярдәмендә барган Аллаһ-инсан диалогында Аллаһ колына һичшиксез җавап бирер. («Гафир», 60) Аллаһ инсанга кан тамырыннан (аортадан) күпкә якынрак булу сәбәпле дога укыган инсанның кычкырып чакыруы, ачыргалануы, купшы сүзләрнең кирәге юк. Догада иң мөһиме сүзләр түгел, ә ихлас һәм самимилектер.

Аллаһ Рәсүле (с.) Мәккәдән Таифкә исламга чакырырга киткән иде. Таифтә аңа ташлар аттылар, башын һәм аякларын яраладылар. Кире кайтканда бер йөземлектә качып торганда шушы доганы укыган:

Аллаһым! Көчемнең көчсезлеккә әйләнүен, чарасыз калуымны, халык каршында кадерсез күренүемне фәкать сиңа күрсәтәм, сиңа шикаять итәм.

Әй мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе! Җәберләнгәннәрнең Раббысы син!

Аллаһым! Мине холыксыз, намуссыз бер дошман кулына төшермә, хәтта тормышымның тезгеннәренә ия булган туганнан алып дуска кадәр мине мохтаҗ итмә, мәрхәмәтлесең.

Аллаһым! Әгәр миңа ачулы түгелсең икән, башымнан уза торган бәлаләргә һич бирешмәм. Синең хакимлегең боларны күрсәтмәячәк кадәр киң. Сиңа сыенам. Синең йөзеңнең нурына сыенам. Бөтен караңгылыкны яктырткан, дөнья вә ахирәт эшләренең яхшыруы Аңа бәйле булган нурга сыенам.

Аллаһым! Син разый булуга кадәр, кичерүеңне телим. Бөтен куәт, һәртөрле кодрәт фәкать синдәдер».

Доганың башы да, ахыры да Аллаһка шөкер итүдер.

*Рәүф ПӘХЛЕВАН ГҮР*
*2 Рәҗәп 1418 / 3 ноябрь 1997*
*Истанбул – 2002*

www.darulkutub.com

# ПСИХОЛОГЛАР КҮЗЛЕГЕННӘН ДОГА

Доганың күп төрле психологик тәэсире барлыгына һәм теоретик, һәм гамәли күзәтүләр нәтиҗәсендә ачыклык кертелгән. Дога инсанның тойгыларына, аңына, үз-үзен тотышына, рух һәм тән саулыгына, хәтта матди хәле үзгәрүенә дә йогынты ясый ала. Икенче төрле әйткәндә, дога бер төр зиһни һәм органик үзгәрүдән гыйбарәт. Фәкать дога укыган кешенең казаначак психологик кыйммәтләренең бөтене белән ул кешенең инануына бәйле булуы да хак. Самими инанып укылган



www.darul-kutub.com

доганың тәэсире шиксез. Доганың чын кыйммәте дога белән юаныч табудыр; шулай итеп инсанның ихтыяры Аллаһның ихтыярына буйсына.

Психологлар тарафыннан ясалган тикшеренүләр буенча, дога – илаһи ярдәм алу өчен рухи механизм, аны бөтен кеше дә куллана ала. Ул кешенең дөньяларны яралтучы чиксез кодрәт иясе булган Аллаһка якынлашуы да әле. (Каррель, Дога: 6). Дога – Аллаһның бертуктамый ташып торган яратуына кол тарафыннан бирелгән җаваптыр.

Мөхәммәт Икбал карашы буенча, дога вә гыйбадәт – һич бер җирдән ярдәм көтмәгәндә, борчуларың белән бүлешү. Табигатьне гыйльми яктан тикшерү безне Аллаһ Тәгаләнең барлыгына ышануга китерер.  Бу да, бер яктан караганда, дога вә гыйбадәт. Бу -



www.darul-kutub.com

эзләнүләрнең бер нәтиҗәсе (Исламда дини төшенүнең яңадан корылуы, 105). Бу Коръәндә еш телгә алына.

Бер аятьтә Аллаһның барлыгын иң яхшы сизеп, Аның кодрәтен иң тәэсирле рәвештә аңлатучыларның галимнәр булуы хакында болай диелә:

«Күкләрнең вә җирнең яралтылышында, төн вә көннең бер-бер артлы килеп китүендә акылларына ия булучыларга уйлау өчен этәргечләр бар. Алар [ауылларына ия булучылар] Аллаһны аягөсте, утырганда һәм ятканда Аллаһны искә алырлар, күкләрнең вә җирнең яралтылуы хакында уйларлар һәм болай диярләр: «Әй Раббыбыз! Син боларны ялганлап (мәгънәсез итеп) яралтмадың. Син камилсең (һәртөрле җитешсезлекләрдән азатсың). Безне җәһәннәм газабыннан сакла! (Әли Имран: 190-191).

Гомумән, дога инсанның бөтен рухи дөньясын көч вә җанлылык белән тәэмин итә. Джеймс моны кешенең эчендә яки тышында булган яшерен энергия эшчәнлеге буларак шәрехли. Ягъни дога ярдәмендә Аллаһ белән корылган элемтә аркасында илаһи энергиянең тәэсире рух ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, куркуларны бетерергә һәм шул юл белән тышкы дөньяны үзгәртергә алына. Шулай итеп, дога гадәти бер хәлдә кешенең көчен арттыруда, аң дәрәҗәсен күтәрүдә һәм киңәйтүдә, гадәттән тыш эшләрне башкаруда көч, куәт һәм җитешлек алу өчен бер чара. Күңелсез, борчулы һәм киеренке хәлдә исә доганың тәэсире «тынычлык һәм рәхәтлек» рәвешендә үзен күрсәтә. Доганың моны тәэмин итәчәк тәэсире догада кулланылган сүз һәм уйлар ар-

www.darul-kutub.com

касында түгел. Чынлыкта, сүз вә уй доганың мәҗбүри өлеше булмаганнан, кеше болардан башка да дога кыла ала һәм Аллаһка юнәлә. Дога ул кешенең үзе аңламаган теләкләре дә әле.

Дога белән барлыкка килгән көч вә сөенечнең артуы нерв системасының яңа бер тәртипкә китерелүенә бәйле. (Мариньер, Дога: 44).

Дога бөтен дөнья белән элемтәне һәм дөньяга кагылышлы уйларны үзгәртер, кеше бөтенләй башка хисләр белән яши башлар. Дога яңа сыйфатларның барлыкка килүнә этәрер. Тәҗрибәләребез шуны күрсәтте: әкерен тавыш белән әйтелгән җитди сүзләр подсознаниега тәэсир итә. Дога җан һәм тән авыруларын җиңәргә ярдәм итә. Мондый дога, аңның караңгы бүлемнәренә үтеп кереп, кешедә тынычлык барлыкка китерә.

www.darul-kutub.com

Дога кешедә ихтыяр көченең үсүенә этәрер, кеше үзендә төрле авырлыкларны җиңәрлек көч тояр, шуңа үз-үзен башкача тота башлар. Дога аркасында тирә-яктагы дөнья кеше өчен зуррак әһәмият казаныр.

Доганың әхлак һәм характерга да бик зур тәэсире бар. Джеймс доганы кешеләрнең күбесендә әхлакый сәламәтлек һәм аңа бәйле физик саулыкта доганың зур әһәмияткә ия булуын әйтә. Каррель шуңа ишарә итеп, еш укылып, гадәткә әйләнгән доганың характерның чистарынып өлгерүенә юл ача алачагын белгертә. (Каррель, Дога, 32).

Дога кешегә үз-үзен бер бөтен итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә, чөнки аның аңы киңәя. Дога гүя кешенең эчендә яктыртучы утны кабыза һәм кеше үзен күрә башлый. Эгоиз-

www.darulkutub.com

мын, саранлыгын, хаталарын, горурлыгын таный. Нәтиҗәдә, ул әхлакый вазыйфаларын башкарырга әзерлек хәленә килә, фикер һәм зиһен тыйнаклыгын үзендә булдырырга тырыша, үсә, өлгерә. Начарлык һәм газаплануларга каршы сабырлык һәм таяну ноктасы барлыкка килеп, куәт казана. Дәвамлы дога кылган кешеләрдә бурыч һәм җаваплылык тойгысы арта, көнләшү һәм явызлык кылу теләге кими. Башкаларга яхшылык итү һәм мәрхәмәтлелек күрсәтү хисләре хакимлек итә башлый. Фикер һәм зиһен үсеше тигез булганнар арасында үткәрелгән тикшеренүләрдә характер һәм әхлак кыйммәтен кайвакыт дога кылганнарда һич кылмаганнарга караганда югары булуы күзәтелә (Каррель, Дога: 35).

Дога кылу кешедә зиһен, рух һәм



www.darulkutup.com

әхлак көчләренең тагын да артуына, өмет һәм инануның җанлануына, кайгыру, күңелсезләнү һәм куркуның басылуына һәм кеше буларак иң югары дәрәҗәгә җитеп формалашуына китерә.

## ДОГАНЫҢ ӘДӘБЕ

Ислам башка гыйбадәтләрендә кебек, догада да билгеле бер шартларның үтәлүен сорый. Алар буенча, дога кылган кешенең шушы гамәленә туры килә торган әдәпне саклавы кирәк. Мәсәлән, доганың бер төре булган намазда колның үз-үзен тотышы дә билгеләнгән. Бу хәрәкәтләр тыштан караганда инсанның хөрмәт һәм сыенуын билгеле бер тәртип буенча үтәлүен тәэмин итә, намаз үзе исә Аллаһның хозурында көчсезлеген, җитешсезлеген, Аллаһка шөкер һәм ярдәм теләкләрен белдерүне аңлата. Намазда һәм һәр-

www.darul-kutup.com

төрле догада әдәпнең нигезен колның тәкәбберлек, эшне күрсеннәр дип эшләү, дорфалык һәм акылсызлык кебек әхлакый җитешсезлекләрдән чистарынуы тәшкил итә. Бер аять буенча, Аллаһның хозурында булганнар масаймаслар, киресенчә, Аның бөеклеген мактап, сәҗдәгә китәрләр. Доганың чын күңелдән һәм тавышсыз (кычкырмыйча) кылынуы кирәк. (Әгъраф: 205-206). Киресенчә эшләү Аллаһның ризасызлыгына китеүе, моның чикне узу булуы башка бер аятьтә әйтелә.

Кол дога кылганда Аллаһка игътибар, хөрмәт һәм өмет белән мөрәҗәгать итәргә тиеш. (Әгъраф: 55-56). Каты тавыш белән тәкбир әйткән кайбер мөселманнарга Хәзрәти Пәйгамбәр каршы булган һәм: «Сез чукрак булган, еракдагы затка түгел, һәрнәрсәне күргән һәм тойган Аллаһка дога кы-

ласыз», дигән. (Бохари, Дәгъват: 50). Моңа кагылышлы бер аятьтә Аллаһның кешегә якын булуы, дога кылучының догасына җавап бирүе әйтелгән. (Бәкара: 186).

Аллаһ Рәсүле (с.) кешенең доганың йөрәк белән кылуын, теләгенең төгәл итеп, гади тел белән әйтелүен, кабул булмады дип әйтелмәвен, сорауның дәвам иттерелүен, җай булса теләкнең өч тапкыр кабатлануын киңәш иткән. (Бохари, Дәгъват: 20 22).

Имам Газали ун дога әдәбен санап күрсәткән:

### *1. Мактаулы вакытларны эзләү*

Мәсәлән, ел эчендә – гарәфә көннәре, айлар арасында – Рамазан, атнада – җомга, төннәрен – сәхәр вакытында дога

www.darul-kutub.com

кылу. Шуңа өстәп, Коръән Кәримдә: «Сәхәр вакытында (төн ахры, иртәнге намазга бераз вакыт кала) алар тәүбә иттеләр», дип боерган. (Зәрият: 18).

Хәзрәти Пәйгамбәр дә болай кушкан.

«Төннең соңгы өчтән бере кадәр вакыт калгач, Аллаһы Тәгалә беренче кат күк йөзенә иңә (мәрхәмәтен, гафу итүен бирүе турында сүз бара) аннан колларына мөрәҗәгать итә: «Мин Хуҗа! Юкмы тәүбә итүче? Аны кичерәм. Юкмы миннән теләүче? Аңа теләгәнен бирәм. Юкмы дога кылучы? Догасын кабул итәм», дигән. (Бохари, Дәгъват: 52).

Хәтта уллары Якуптан (г.с.) алар өчен Аллаһтан гафу үтенүен сорагач, ул: «күпмедер вакыттан сезнең өчен Раббымнан гафу сорармын», (Йосыф:



www.darul-kutub.com

98) – дип кайбер галимнәр фикеренчә, сәхәр вакытын көтү өчен әйтте.

## *2. Мактаулы хәлләрдән файдалану*

Хәзрәти Пәйгамбәр болай дигән:

«Азан белән камәт арасында укылган дога кире кагылмас» (Тирмизи, Нәсаи).

Әбү Һурәйрә (р.г.) болай куша: «Күк ишекләре Ислам гаскәре белән кяферләр армиясе очрашканда, яңгыр яуганда һәм фарыз намазлары кылынганда ачылыр. Бу вакытлардан файдаланып, дога кылыгыз».

Хәзрәти Пәйгамбәр (с.) болай ди:

«Ураза тотучының догасы кире кагылмас». (Тирмизи).

«Колның Аллаһка иң якын вакыты –

www.darulkutub.com

аның сәждәгә киткән чагы. Сәждәдә Аллаһка күп догалар кылыгыз».

«Рөкугъ белән сәждәдә Коръән укудан тыелдым Рөкугъта Раббыгызны олылагыз, сәждәдә дога кылыгыз. Чөнки сәждә – догаларның кабул булуы өчен иң кулай вакыт». (Мөслим).

### *3. Кыйблага юнәлеп дога уку*

Җәбир бине Абдулла (р.г.) Хәзрәти Пәйгамбәрнең, Гарәфәттә кыйблага юнәлеп, кичкә кадәр дога кылуы хакында сөйләгән.

Хәзрәти Пәйгамбәр (с.) әйтүенчә:

«Бәгъзе адәмнәр күккә карап дога кылудан ваз кичсеннәр. Юкса Аллаһ аларның күзләренең нурын алыр. (Мөслим, Саләт: 26).

www.darulkutub.com

Әнәс (р.г.) риваяте буенча:

«Аллаһ Рәсүле дога кылганда култык асты күренгәнчегә кадәр кулларын күтәрер һәм догада бармакларын селкетми иде. (Мөслим). Ибне Габбас (р.г.) та моны раслый.

Хәзрәти Пәйгамбәр дога кылганда учларын куша һәм учларының эчен йөзенә таба ача иде.

### *4. Доганы үз эчеңнән генә уку*

Аллаһ болай куша:

«Раббыгызга күңелдән һәм үз эчегездән генә дога кылыгыз». (Әгъраф, 55).

«Зәкәрия Раббысына тавышсыз гына (ихластан, башкалар ишетмәслек итеп) дога кыла иде». (Мәрьям: 3).

www.darul-kutub.com

Хәзрәти Пәйгамбәр (с.) болай ди:

«Эчтән генә укылган бер дога кычкырып укыган җитмеш догага тора». (Фәйд'уль-Кадир: 3:527).

## *5. Догада ясалма сүзләрдән саклану*

Дога кылучы ишек кагучы теләнче кебек. Тыйнаклык, самимилек белән теләгәндә, ясалма сүзләр сөйләми.

Аллаһ болай ди:

«Раббыгызга күңелдән һәм үз эчегездән генә дога кылыгыз. Ул чиктән ашып киткәннәрне сөймәс». (Әгъраф, 55).

Хәзрәти Пәйгамбәр (с.) болай дигән:

«Догада ясалма сүзләрдән качыгыз. «Аллаһым! Синнән җәннәт һәм

www.darulkutub.com

мине җәннәткә якынлаштырачак сүз вә гамәлләр телим, җәһәннәмнән һәм җәһәннәмгә якынлаштыра торган сүз вә гамәлләрдән сиңа сыенам», – дию җитә. Киләчәктә шундый инсаннар киләчәк ки, алар дога һәм чисталык чиген ашырлар».

### *6. Доганы ихлас белән уку*

Ихлас (хушугъ) дигәндә Аллаһтан курку һәм шул ук вакытта Аңа өметләнеп дога кылу аңлашыла.

Хушугъ Аллаһның бөеклеге, кодрәте каршында колның көчсезлеген хис итеп, бу хис белән калебнең соң чиктә хөрмәтле булуны аңлата.

Хушугънең кеше тәнендә чагылышы исә тынычлыктыр.

«Коръән Кәрим»дә болай диелә:



www.darul-kutub.com

«Мөэминнәр өчен Аллаһ искә алынганда, Коръән укылганда, дини бер үгет алганда, Коръән каршында (аның Аллаһтан икәнен белә торып) рәхәтлек, йомшаклык, илһам киләчәк вакыт җитмәдеме әллә? Элегрәк Китап алганнарга (христиан һәм яһүд) ике пәйгамбәр арасы озак вакыт булып тоелып, йөрәкләре ташка әйләнгәннәргә охшаш булмасыннар. Аларның күбесе начарлык кылыр (йорәкләре дә дәшмәс) (Ягъни әй мөселманнар, сез купме ел гыйбадәт кылганнан соң иманыгыз нык булырга тиеш түгелме, ямьсез теллек, ялкаулык, гонаһны калдыру кирәкмәсме?) (Хәдид: 16).

## *7. Догада тәвәккәл һәм өметле булу*

Дога кылганда тәвәккәл һәм кабул булачагына өмет итеп, Аллаһтан яхшы нәтиҗә өмет итү.



www.darul-kutub.com

Хәзрәти Пәйгамбәр (с.) кушты:

«Догакылганда:«Аллаһым!Теләсәң– мине кичер, теләсәң – миңа мәрхәмәт кыл» димәгез. Теләгәнегезне шиксез рәвештә Аллаһтан сорагыз. Шулай итеп Аны мәҗбүр итә торган бернинди көч тә юктыр. (Бохари-Мөслим).

«Догага аның кабул булачагына өметләнеп керешегез. Чөнки аның кабул булуы Аллаһ өчен җиңел». (Ибн-и Хиббан).

### *8. Доганы кат-кат уку*

Ибни Мәсгүд (р.г.) сөйли:

«Хәзрәти Пәйгамбәр (с.) дога кылганда догасын өч тапкыр укый иде. Аллаһтан берәр нәрсә сораганда да өч тапкыр сорый иде».

Хәзрәти Пәйгамбәр (с.) әйтә: Аллаһы Тәгалә догагызны кабул итер. Бил-

www.darul-kutub.com

геле, «Дога кылдым, әлегәчә кабул булмады» дип ашыкмагыз. Аллаһтан күп тапкырлар сорагыз. Чөнки сез бөеклек иясеннән телисез. (Бохари).

«Берәрегез берәр нәрсә теләп, теләге кабул булганда «Яхшылыклары, мәрхәмәте белән танылган Аллаһны олылыйм», дисен. Кабул булмаган очракта: «Ни генә булса да Аллаһка шөкер», – дисен». (Бәйһаки).

### *9. Доганы бисмиллә белән башлау*

Доганы Аллаһның исемен телгә алып, Аны олылап, соңрак Рәсүленә сәлам китереп башларга кирәк. Сәлам бин Аква болай аңлата:

«Аллаһ Рәсүлененең «Сүбхәәнә Раббийәл-галиййил-әгьлә-л-вәһһаб» диюдән һичбер догага кушып әйткәнен ишетмәдем. (Хаким: 1/498).

www.darul-kutub.com

Берегез дога кылганда Аллаһка мактау китереп башласын, аннары Аллаһ рәсүленә салават укысын, болардан соң теләгәнен сорасын. (Тирмизи, Дәгъват: 66).

### *10. Доганы эчке әдәп белән уку*

Бу да тәүбә итү, башка кешедән гафу алу. Бу – доганың кабул булуында иң мөһим фактор. (Газали: 1/280).

## Дога ярдәмендә җан һәм тән саулыгын саклау

Гыйбадәтләрнең максаты – инсанның җанын-тәнен таза-сау тоту, аны рухи һәм бәдәни авырулардан саклау, хәтта малының саулыгын саклау. Чөнки намаз кебек бер гыйбадәт таһәрәт һәм госел алу шарты кабул итү белән тән чисталыгын, бигрәк тә на-

www.darul-kutub.com

маз һәм ураза, инсанның рухи чисталыгын, зәкәт – инсанның малының чисталыгын тәэмин итүче корал. Димәк, бөтен гыйбадәтләрне терапия буларак билгеләргә мөмкин. Шундый авырулар бар ки, аларның сәбәбе микроб һәм кешенең тәне пычрану. Кайбер авырулар исә микроблар белән бәйле түгел, ә рухи функцияләренең һәм яшәешенең пычрануы сәбәбенә кайтып кала. Фәкать җан белән тән арасында аерма булмаганда гына бер тән хасталыгы кайвакыт рухи тормышка да авыру китергән кебек, рухи хасталык та тән саулыгына тәэсир итә ала. Андый хәлдә тулы һәм сәламәт кешелек өчен тәннең дә, җанның да бер дәрәҗәдә сәламәт булуы кирәк. Иман һәрнәрсәдән алда инсанның җан һәм йөрәк чисталыгы дигәнне аңлата. Кеше Аллаһка инану белән үзен баш-

ка нәрсәләрдән арындыра, Аллаһ аңны тиешенчә кора; кяферлек исә пычрану, йөрәкнең каралуы дигәнне белдерә. Иман инсанның гүзәл, чиста һәм дөрес эшләр эшләячәгенә сәбәп булган кебек, көферлек тә җирәнгеч һәм ялгыш эш эшләвенә этәрә. Инану кешенең эчендә хозурлык хисе тудырыр.

«Америка табиблары һәм хирурглары берләшмәсе» әгъзасы доктор Гарольд Гейн уртача 44 яшьтә булган 176 эшче ирне тикшергән. Боларның яртысы нерв киеренкелеге булган өч авыруның берсенә дучар булганнарын күрде. Бу авырулар: йөрәк кагуы, язва һәм кан басымы югары булуы.

Докторларның бу мәсьәләдә сабыр итү киңәшләре «Коръән Кәрим» киңәшләре янында күпкә көчсез күренә:

«Аллаһка таян, вәкил буларак Аллаһ җитә». (Әл-Гыймран, 173).

«Аллаһ теләгәненә күп ризык бирер, теләмәгәненә – аз». (Сад: 25).

«Җир йөзендә һәрбер җан иясенең ризыгы Барлыкка китерүче тарафыннан билгеләнгән һәм бирелгән. Ул аларның бөтен яшәү этапларын белә (кайда булганнарын, әле туганчыга кадәр булган тормышларын һәм ахырларын). Болар барысы да саклanuчы китапта язылган». (Худ, 6).

«Әгәр Аллаһ (Раббы) үзенең чиксез байлыкларыннан кешегә ниндидер чыганак бирә икән (исәнлек булсынмы, күңел тынычлыгы, белем, хикмәт, алдынгы карашлы фикер һәм аларны тормышка ашыру өчен мөмкинчелекләр ме), җирдәге һәм күкләрдәге беркем дә моны туктата алмас. Әгәр берәрсенә

www.darul-kutub.com

мөмкинчелек бирмәсә, бер кем дә бирэ алмас. [бу законны белеп яшәү, биеклеккә менү һәм түбән тәгәрәүләрне үткәреп җибәрү җиңелрәктер]...». (Фагтыйр: 2).

Психологлар беравыздан күңел белән бәйле авыруларны дәвалауда һәм алардан саклануда иманның иң мөһим фактор булуы хакында сөйлиләр. Һарвард университетының фәлсәфә профессоры Уильям Джеймс: «Җан сызлануларына иң зур дәва – ул һичшиксез имандыр», ди. Шул ук вакытта психологлар нерв киеренкелегенә һәм борчылуга каршы иң яхшы шифа дип дусты булуны саныйлар. «Аллаһтан яхшырак дустым булырмы? Ул гел минем белән!» – дигән фикер бу канунның иң яхшы чагылышы түгелме? Кешене тынычландырачак бер дусты булырга тиешлеге турындагы сүзләр Коръәнгә кайдан

www.darul-kutub.com

килә ала? Аллаһ болай ди: «Әгәр колларым синнән минем турында сорасалар, белсеннәр: мин якын. Мине чакырган вакытларында сораганның догасына җавап бирермен». (Бәкара сүрәсе, 186 аять). «Без аңа аортасыннан да якынрак». (Каф, 16).

«Өч кеше яшерен сөйләшмәс ки, дүртенчесе Аллаһ булмаса». (Мөҗадәлә, 7).

Нәтиҗә буларак Аллаһның шул файдалы сүзен ишетү, җанга бөек рәхәтлек бирер:

«Һәр авырлык белән бергә җиңеллек бар, һәр авырлык белән бергә җиңеллек бар». (Инширах, 4-5).

«Коръән Кәрим» йөрәкнең һәм хиснең бөтен бер иман белән тәэсир итәчәген камил иман белән Аллаһка бәйләнүне, Аңа дога кылуны киңәш



www.darul-kutub.com

иткән. Аллага иманга, аңа тәвәккәлгә һәм Аңа дога кылып, аны чакырган аятьләр «Коръән Кәрим»нең бик күп урыннарында кабатлана. Бөтен пәйгамбәрләрнең беренче чакырулары бердәнбер Аллаһка иман китерү һәм Аңа гыйбадәт кылу. Бу бөтен диннәрнең асылы. Чөнки диннең (күктән иңдерелгән дин) нигезендә Аллаһка иман китерү һәм Аңа гыйбадәт кылу. Төрле дәверләрдә килгән пәйгамбәрләр гел шуны аңлатканнар.

«Без Нухны кавеменә җибәрдек, Ул «Әй, кавемем! Аллаһка гыйбадәт кылыгыз», диде». (Мөэминүн: 23).

Ибраһимны да җибәргән идек. Кавеменә: «Аллаһка гыйбадәт кылыгыз (кушканын (фарзларын) үтәгез, тыйганыннан тыелыгыз), аннан куркыгыз», диде. Бу сезнең өчен иң яхшысы, белсәгез иде!» (Үрмәкүч: 16).



www.darul-kutup.com

Психологик һәм педагогик тикшеренүләр күрсәткәнчә, Аллаһка инану, Аңа ышану һәм дога кылу бөтен рухи аыврулардан, нерв киеренкелегеннән, ямансулык һәм куркудан башланган матди авырулардан котылу һәм саклануның иң зур дәвасы. Бу уңайдан доктор Алексис Каррель болай ди:

«Шуны әйтә алам: намаз – бүгенге көнгә хәтле билгеле булган куәт һәм хәрәкәт чыганакларының иң зурысы. Мин шәхсән үзем дәвалаган авырулар арасында моңа шактый үрнәкләр күрдем. Күпме авыру булгандыр, мин аларны дәвалауда уңышка ирешә алмаган идем. Медицина көчсез булган вакытта эшкә намаз керешә һәм бик тиздән авырулар китә. Без намаз кылганда галәм белән куәтле элемтә булдырабыз. Аллаһка зарланып, үз катыннан

www.darulkutub.com

безгә бер нур бирүен телибез. Аннан тормышның көчсезлекләренә каршы ярдәм сорыйбыз. Хәтта бары ялвару да көчебезне кайтарырга җитәрлектер.

Аллаһка ялвару гел инсанның үзенә иң күркәм нәтиҗә булып әйләнеп кайта. Шулай булмый калуына бер генә мисал да китерә алмыйбыз. (Борчылуны калдыр, яшәргә тырыш: 229).

Медицина тикшеренүләреннән күренгәнчә, тән хасталыкларының иң мөһим сәбәпләре инсанның гомуми халәте һәм нерв системасының какшавыдыр. Аллаһка иман юлы белән рух дәвасы – медицинаның мөһим сәбәбе. Психологлар бу фикерләрен фикеләнүләргә урын калдырмаслык итеп белдерә. Доктор Брил болай ди:

«Чыннан да диндар булган инсан беркайчан да рухи авыруга дучар бул-



www.darul-kutub.com

мас». Мәшһүр психолог Дейл Карнеги болай ди:

«Күпчелек психологлар куәтле иманның һәм дингә тартылуның күңел боеклыгы, борчылу һәм нерв киеренкелеген җиңәчәк, бу авыруларга шифа бирәчәк ике мөһим фактор булуын аңлыйлар».

## Авыру һәм сызланулардан укыла торган дога

Тирмизи хәдисләр җыентыгындагы Әнәс бине Мәликнең риваяте буенча, Рәсүлүллаһ (с.) болай куша торган булган:

«Берәр җиреӊ авырганда кулыңны шул авырган җиргә куй һәм шушы доганы кабатла:

بِسْمِ اللهِ أَعُوذُ بِعِزَّةِ اللهِ وَ قُدْرَتِهِ مِنْ شَرِّ مَا أَجِدُ مِنْ وَ جَعِى هَذَا.

**«Бисмилләһи әгүүзү би гиззәт-илләһи үә кудьратиһи мин шәрри мәәә әҗидү мин уәҗәгый һәәзәә».**

*Аллаһ исеме белән. Башыма төшкән бу авыруның көченнән Аллаһның бөеклегенә һәм кодрәтенә сыенам.*

## Мәгарәдәге кешеләр догасы

Коръәндә хикәяләнгәнчә, бер төркем кеше инанулары аркасында җәберләнүләреннән качып, мәгарәгә яшеренгәч, шушы доганы укыган:

رَبَّنَا اَتِنَا مِنْ لَدُنِكَ رَحْمَةً وَ هَيِّئْ لَنَا مِنْ أَمْرِنَا رَشَدًا

**«Раббәнәә әәтинәә мин ләдүңкә рахмәтәү үә һәййи-э ләнәә мин әмринәә рашәдәә».**

*Әй Раббыбыз! Безгә үз катыңнан мәрхәмәт бир һәм шушы эшебездән котылу юлы әзерлә. (Кәһәф, 10).*



www.darulkutub.com

Теләсә нинди эшне башлаганда бу дога укылыр.

## Баш авыртканда укыла торган дога

Аллаһ Рәсүле (с.) баш авыртканда бу доганы укырга киңәш итә иде:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ . بِسْمِ اللهِ الْكَرِيمِ وَ
أَعُوذُ بِاللهِ الْعَظِيمِ مِن شَرِّ كُلِّ عِرْقٍ نَارٍ وَ مِنْ
سَرِّ حَرِّ النَّارِ.

**«Бисмилләәһ ир-рахмәән ир-рахиим.**

**Бисмилләһиль-кәриим. Үә әгүүзү билләһ-иль- гәзыйм мин шәрри күлли гиркый нәәри үә миң шәрри хәррин-нәәр».**

*Рахман вә Рәхим булган Аллаһ исеме белән. Кәрим булган Аллаһ исеме белән. Һәртөрле авыруның зыяныннан һәм җәһәннәм уты начарлыгыннан бөек Аллаһка сыенам. (Мевәһибуль-Ләдунния).*

www.darul-kutub.com

## Бәлагә юлыккан кешене күргәч укыла торган дога

Рәсүлүллаһ (с.): «Бәлагә юлыккан кемне дә булса күргән кеше бу доганы укыса, аңа андый бер бәла дә кагылмас», дигән.

الْحَمْدُ لِلّهِ الَّذِى عَافَانِى مِمَّا ابْتَلاَكَ بِه وَ فَضَّلَنِى عَلَى كَثِيرٍ مِمَّنْ خَلَقَ تَفْضِيلاً.

**«Әлхәмдүлилләһ илләзи гәәфәәнии риммә-бтәләәкә биһии үә фәддаләнии гәләә кәсиирин миммән халәка тәфдыйлә».**

*Син тотылган бәладән миңа саулык бир һәм яратылганнарның купчелегенә мине мәрхәмәтле кылган Аллаһка мактау булсын. (Тирмизи, Дәгъват: 3428).*

www.darul-kutub.com

## Билгеле бер вакытта уяну өчен укыла торган дога

Билгеле бер сәгатьтә уянырга теләгән кеше, Кәүсәр сүрәсен өч тапкыр ихластан һәм Аллаһка ышану белән укып ятса, теләгән сәгатендә уяныр.

***Кәүсәр сүрәсе:***

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
إِنَّآ أَعْطَيْنَاكَ الْكَوْثَرَ ۗ * فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ۗ
* إِنَّ شَانِئَكَ هُوَ الْأَبْتَرُ.

**«Бисмилләһ ир-рахман ир-рәхим.**

**Иннәәә әгьтайнәәкәль-кәүсәр. Фәсалли ли раббикә уә-нхәр. Иннә шәәниәкә һү әль-әбтәр».**

*Рахман вә Рәхим булган Аллаһ исеме белән.*

*Чынлыкта без сиңа Кәүсәрне (җәннәттәге елга) бирдек. Шул хәлдә Раббыңа намаз кыл (Корбан гаете намазы) һәм корбанга (хайван) чал. Асыл нәселе беткән – сиңа нәфрәт тоткан берәүдер (сине үртәшкән).*

www.darul-kutub.com

## Бурыч вә гөнаһтан саклану өчен укыла торган дога

Бу Хәзрәти пәйгамбәрнең (с.) өйрәткән догаларыннан:

اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْكَسَلِ وَ الْهَرَمِ و
الْمَعْسَمِ وَ الْمَغْرَمِ وَ مِنْ فِتْنَةِ النَّارِ وَ عَذَابِ
النَّارِ وَ مِنْ شَرِّ الْغِنَى وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ
الْفَقْرِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْمَسِيحِ الدَّجَّالِ

**«Аллааһүммә иннии әгүүзү бикә минәль-кәсәли үәль-һәрәми үәль-мәгъсәми үәль-мәгърами үә мин фитнәтин-нәәр үә мин шәрриль-гыйнә үә әгүүзү бикә мин фитнәт иль-фәкъри үә әгүүзү бикә мин фитнәтиль-мәсиихид-дәҗҗәәл».**

*Аллаһым! Ялкаулыктан, картлык авырлыгыннан, гөнаһка гадәтләнүдән, бурычтан, кабер фетнәсе вә кабер газабыннан, җәһәннәм фетнәсе вә җәһәннәм газабыннан, байлык начарлыгыннан, фәкыйрьлек фетнәсеннән, ялганчы*

www.darul-kutub.com

*Мәсихнең (Дәҗҗалның) фетнәсеннән сиңа сыенам. (Бохари: 7/159).*

## Бурыч түләүне җиңеләйтү өчен

Хәзрәти Галиның (р.г.) сөйләве буенча, аңа билгеле бер сумма түләү шарты белән коллыктан котылу килешүе төзегән берәү килгән һәм: «Төзелгән килешүдәге акчаны түләмәдем. Миңа ярдәмче бул», дигән. Моңа каршы Хәзрәти Али болай дигән: «Игътибар ит. Сиңа сүзләр өйрәтәчәкмен. Аларны миңа Аллаһ Рәсүле (с.) өйрәткән иде. Синең Ухуд тавы кадәр бурычың булса да, Аллаһ аның түләнүен тәэмин итәчәк. Болай дип әйт:

اللّٰهُمَّ أَكْفِنِى بِحَلاَلِكَ عَنْ حَرَامِكَ وَ أَغْنِنِى بِفَضْلِكَ عَمَّنْ سِوَاكَ.

**«Аллааһүммә әкфинии бихәләәликә гән**



www.darul-kutub.com

**хәраамикә үә агънини бифәдъликә гәммән сиүәк».**

*Аллаһым! Миңа, хәрамнан сакланып, хәләл белән генә канәгатьләнергә насыйп әйлә. Зинһар өчен, синең мәрхәмәтеңнән кала башкасына мохтаҗлык әйләмә. (Тирмизи, Дәгъват: 3558).*

## Кризис хәлендә калгач укыла торган дога

Кризис хәленә төшкән, нерв авыруына дучар булган инсаннар өчен Мөэминүн сүрәсенең 115 һәм 116 нчы аятьләрен 21 көн дәвамында көнгә 21 тапкыр укырга киңәш ителгән. Моны укыган мөселманнар чынлап та моны кулланганнарын әйткәннәр. Ул аятьләр:

أَفَحَسِبْتُمْ أَنَّمَا خَلَقْنَاكُمْ عَبَثًا وَأَنَّكُمْ إِلَيْنَا لَا
تُرْجَعُونَ * فَتَعَالَى اللَّهُ الْمَلِكُ الْحَقُّ ج لَا إِلَٰهَ إِلَّا
هُوَ رَبُّ الْعَرْشِ الْكَرِيمِ

**«Әфәхәсибтүм әннәмәә халәкънәкүм га-**

www.darul-kutub.com

**бәсә үә әннәкүм иләйнәә ләә түрҗәгүүн. Фәтәгәәләллаһүль-мәликүль-хәкъ. Ләәә иләәһә иллә һүә раббүль-гәрш иль-кәриим».**

*«Сезне болай гына, мәгънәсезгә, кызык өчен яраттык, безгә кайтарылмассыз дип уйладыгызмы? (үлгәннән соң туфрак булырбыз дидегезме?) Чын Хуҗа бөтенесеннән дә өстен (шулай була торып, ул берәр нәрсәне мәгънәсез итеп ярата аламы?) Аллаһтан башка илаһ юк, ул кыйммәтле гареш иясе». (Мөэминүн: 115-116).*

## Җиһадка кагылышлы догалар

رَبَّنَا أَفْرِغْ عَلَيْنَا صَبْرًا وَثَبِّتْ أَقْدَامَنَا وَانْصُرْنَا عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ.

**«Раббәнәәә әфригъ гәләйнә сабран үә сәббит әкъдәәмәнәә үәңсурнәә гәләль-кауми ль-кәәфириин».**

*Әй Раббыбыз! Безгә сабырлык яудыр, адымна-*

*рыбыз нык булсын һәм кяферләр берләшмәсенә каршы көрәшергә ярдәм ит. (Бәкара: 250).*

اللَّهُمَّ أَنْتَ رَبُّنَا وَ رَبُّهُمْ وَ قُلُوبُنَا وَ قُلُوبُهُمْ بِيَدِكَ وَ إِنَّمَا يَغْلِبُهُمْ أَنْتَ.

**«Аллаһүммә әңтә раббүнәә үә раббүһүм үә кулүүбүнәә үә кулүүбүһүм би йәдикә үә иннәмә йагълибүһүм әнт».**

*Аллаһым! Син безнең дә Раббыбыз, аларныкы да. Безнең йөрәкләребез дә, аларныкы да синең кулыңда. Безгә аларны җиңәргә ярдәм итәчәк тә – син. (әл-Әзкар: 189).*

اللَّهُمَّ مُنْزِلَ الْكِتَابُ سَرِيعَ الْحِسَابِ اهْزِمْ الْأَحْزَابَ. اللَّهُمَّ أَهْزِمْهُمْ وَ زَلْزِلْهُمْ.

**«Аллаһүммә мүнзиләль-китәәб сәриигәль-хисәәб иһзимиль-әхзәәб. Аллаһүммәһзимһүм үә зәлзилһүм».**

www.darul-kutub.com

*Аллаһым! Коръәнне иңдергән һәм тиз хисап кылучы Раббым! Дошманнарны тар-мар ит! Аллаһым! Аларны җиңелүгә дучар ит һәм берләшмәләрен кагып ташла. (Әл-Әзкар: 188).*

## Тире авыруларыннан һәм акылдан язудан саклану өчен укыла торган дога

Аллаһ Рәсүле (с.) бу авырулардан шушы доганы укырга киңәш итәр иде:

اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْبَرَصِ وَ الْجُنُونِ وَ الْجُذَامِ وَ سَيِّئِ الْأَسْقَامِ.

**«Аллаһүммә иннии әгүүзү бикә минәль-бәрасый үәль-җүнүүни үәль-җүзәәми үә сәйииль-әскаам».**

*Аллаһым! Тире авыруларыннан һәм акылдан шашудан сиңа сыенам. (Рияду’с-Салихин, Х.1481).*

www.darulkutub.com

## Эренле шеш (чуан) чыгуга укыла торган дога

Риваять буенча, Аллаһ Рәсүле (с.) хатыннарыннан берсе Зәйнәп бинти Җахштан болай: «Синең яныңдагы шифалы үлән, күз үләне, сөрмә һәм яран үләне бармы?» – дип сорады.

Зәйнәп «Әйе» диде. Аллаһ Рәсүле (с.) үләнне сорап алды да, аны ике аяк бармагы арасындагы чуанга куеп, болай диде:

اَللَّهُمَّ مُطْفِئَ الْكَبِيرِ وَ مُكَبِّرِ الصَّغِيرِ , أَطْفِئْهَا عَنِّى.

**«Аллаһүммә мүтъфиәль-кәбиир үә мүкәббирас-сагыйр әтъфиэһәә гәннии».**

*Аллаһым! Син зур нәрсәләрне кечерәйтәсең, кечкенә нәрсәләрне зурайтасың. Аның (чуанның) утын сүндер, миннән китәр. (Әхмәд б. Хәнбәл: 5/370).*

www.darul-kutub.com

## Дәҗҗалның фетнәсеннән саклану өчен укыла торган дога

Аллаһ Рәсүленең (с.) дәвамлы укыган бер догасы:

اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابِ جَهَنَّمَ وَ مِمْ
عَذَابِ الْقَبْرِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْمَسِيحِ
الدَّجَّالِ وَ أَعُوذُ بِكَ مِنْ فِتْنَةِ الْمَحْيَا وَ الْمَمَاتِ.

**«Аллаһүммә иннии әгүүзү бикә мин гәзәәби җәһәннәм үә мин гәзәәбиль-кабри үә әгүүзү бикә мин фитнәтиль-мәсиихиддәҗҗәәл үә әгүүзү бикә мин фитнәтиль-мәхйә үәль-мәмәәт».**

*Аллаһым! Җәһәннәм газабыннан, кабер газабыннан, ялганчы Мәсихнең (Дәҗҗалның) фетнәсеннән, үлем һәм яшәү фетнәләреннән синә сыенам. (Нәвәви, әл-Әзкар: 28).*

www.darulkutub.com

## Җир тетрәгәндә укыла торган дога

Аллаһ Рәсүле (с.) җир тетрәү, сәйл (көчле су ташкыны) һәм давыл кебек казалардан шушы доганы укыган:

اللَّـهُمَّ احْفِظْنِى مِنْ بَيْنِ يَدَيَّ وَ مِنْ خَلْفِى وَ مِنْ يَمِينِى وَ عِنْ شِمَالِي وَ مِنْ فَوْقِى وَ أَعُوذُ بِعَظَمَتِكَ أَنْ أُغْتَالَ مِنْ تَحْتِى.

**«Аллаһүммә-хфәзънии мим бәйни йәдәй-йә үә мин хальфии үә мин йәмиинии үә гән шимәәлии үә миң фәүкый үә әгүүзү би гәзамәтикә ән әгътәәлә мин тәхти».**

*Аллаһым! Алдымнан, артымнан, уңымнан, сулымнан, куктән һәм җирдән килә ала торган афәтләрдән мине сакла. (Әбү Дауд: 1177).*

www.darul-kutub.com

## Теш сызлаганда укыла торган дога

Сахәбәләрдән Абдуллаһ бине Рәвәхә (р.г.) бер көнне Аллаһ Рәсүленә (с.) теше сызлаудан изалануы хакында сөйләгән иде. Рәсүлүллаһ (с.) бәрәкәтле кулын Хәзрәти Абдуллаһның авырткан яңагына куеп, болай диде:

اللَّهُمَّ أَذْهِبْ عَنْهُ سوءَ مَا يَجِدُ وَ فَحْشَهُ بِدَعْوَةِ نَبِيِّكَ الْمَكِينِ الْمُبَارَكِ عِنْدَكَ

**«Аллаһүммәәзһиб гәнһү сүүә мә йәҗидү үә фәхшәһү би дагьүәтии нәбиййикәль-мәкииниль-мүбәәраки гиндәк».**

*Аллаһым! Синең каршыңда мөбарәк һәм мөхтәрәм булган пәйгамбәреңнең догасы белән бу тешнең авыруын ал. (Мевахибуль-Ләдунния: 75).*

www.darul-kutub.com

## Тулгак тотучы хатын янында укыла торган дога

Хәзрәти Фатыйма (р.г.) бала табуы якынлашканда Аллаһ Рәсүле (с.) Умму Сәләмә белән Зәйнәп бинти Җахшка Фатыйма янына баруларын һәм аның янында Аятел Көрси, Фәлак һәм Нәс сүрәләрен вә шушы аяти кәримәне укырга әмер бирде:

(Ибн Сунәни, Амелуль-Яум: 625).

رَبَّكُمُ اللَّهُ الَّذِي خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ فِي سِتَّةِ أَيَّامٍ ثُمَّ اسْتَوَى عَلَى الْعَرْشِ يُغْشِي اللَّيْلَ النَّهَارَ يَطْلُبُهُ حَثِيثًا ۙ وَالشَّمْسَ وَالْقَمَرَ وَالنُّجُومَ مُسَخَّرَاتٍ بِأَمْرِهِ ۗ أَلَا لَهُ الْخَلْقُ وَالْأَمْرُ ۗ تَبَارَكَ اللَّهُ رَبُّ الْعَالَمِينَ .

**«Раббүкүмүллаһу-лләзии халәкассәмәүәти үәль-әрда фи ситтәти әййәмиң сөммә-стәүә галәль-гәрши йүгъшиль-ләйльән-нәһәрә йәтълүбүһү хәсисән. Үәш-шәмсә үәль-камәра**

www.darul-kutub.com

**үән-нүҗүүмә мүсәххаратин би әмриһ. Әлә ләһүль-халку үәль-әмру. Тәбәракәллаһу раббуль-гәәләмиин».**

*Шөбһәсез ки, Раббыгыз күкләрне һәм җирне яралткан Аллаһтыр. Аннаан соң ул гареш өстеннән күтәрелде. Ул төнне көн белән каплар, ә төн белән көннең алмашуы соңга калмас. Ул кояш, ай һәм йолдызларны яратты. Бпрысы да аңа буйсынып әмерләрен үти. Игътибар итегез! Ул яралтучы һәм идарә итүче. Ул мәрхәмәте буенча бөектер, ул галәмнәрнең Раббысы». (Әгъраф: 54).*

## Бала табуны җиңеләйтү өчен укыла торган икенче бер дога

Әхмәд Зыятдин Көмешханәви хәзрәтләренең Мәҗмүгәтүл-Ахзаб исемле китапта бала табуны җиңеләйтү өчен укырга киңәш иткән икенче бер дога:

www.darul-kutub.com

بِسْمِ اللهِ وَ أَلْقَتْ مِا فِيهَا وَ تَخَلَّتْ وَ أَذِنَتْ لِرَبِّهَا وَ حُقَّتْ بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ يَا خَالِقَ النَّفْسِ مِنَ النَّفْسِ يَا مُخْلِصَ النَّفْسِ مِنَ النَّفْسِ وَ يَا مُخْرِجَ النَّفْسِ مِنَ النَّفْسِ.

**«Бисмилләһи үә әлкать мәә фииһәә үә тәхалләт үә әзинәт ли раббиһәә үә хүүккать. Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим. Йә халикан-нәфси минән-нәфси үә йәә мүхълисан-нәфси минән-нәфси үә йәә мүхъриж ән-нәфси минән-нәфс».**

*Аллаһ исеме белән. Җир эчендә булганнарны тышка атып бушануы һә үзенең яралтылышына уңайлы булып Раббына башын игән вакытта. (Иншикак: 4-5). Рахман вә Рәхим булган Аллаһ исеме белән. Әй җанны җаннан яралткан. Әй җанны җаннан барлыкка китергән. Әй җанны җаннан чыгарган Аллаһым! (Мәҗмугатуль-Ахзаб: 1/588).*

www.darul-kutub.com

## Дошман белән очрашкач укыла торган дога

Әбу Муса (р.г.) сүзләре буенча, Аллаһ Рәсүле (с.) бер кавемнән курыккан вакытта болай дигән:

اللَّهُمَّ إِنَّا نَجْعَلُكَ فِي نُحُورِهِمْ وَ نَعُوذُ بِكَ مِنْ شُرُورِهِمْ.

**«Аллаһүммә иннәә нәҗгәлүкә фии нүхүүриһим үә нәгүүзү бикә миң шүрууриһим».**

*Аллаһым! Без сиңа ышыкланабыз, аларның начарлыгыннан сиңа сыенабыз. (Әбү Дауд, Саләт: 1537).*

## Дошман каршысында укыла торган дога

Бу дога Коръән-Кәримдә бар.

Кяфер Җалутка каршы мөэмин Талутның гаскәре кылган дога:



www.darul-kutub.com

رَبَّنَا أَفْرِغْ عَلَيْنَا صَبْرًا وَثَبِّتْ أَقْدَامَنَا وَانْصُرْنَا
عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ

**«Раббәнәәә әфригъ гәләйнәә сабран үә сәббит әкъдәәмәнәә үәңсурнәә гәләль-каумиль-кәәфириин».**

*Йа Рабби! Безгә сабырлык яудыр. Аякларыбызны нык ит. Кяферләр берләшмәсенә каршы безгә ярдәм ит. (Бәкара: 250).*

## Дошманны җиңү өчен укыла торган дога

Хәзрәти Пәйгамбәр (с.) Ислам дошманнарын җиңү өчен мондый дога укыган:

اللَّهُمَّ أَنْتَ رَبُّنَا وَ رَبُّهُمْ وَ قُلُوبُنَا وَ قُلُوبُهُمْ بِيَدِكَ
وَ إِنَّمَا يِغْلِبُهُمْ أَنْتَ.

**«Аллааһүммә әңтә раббүнәә үә раббүһүм**

www.darul-kutub.com

**үә кулүүбүнәә үә кулүүбүһүм би йәдикә үә иннәмәә йәгълибүһум әңтә».**

*Аллаһым! Син безнең дә Раббыбыз, аларныкы да. Безнең йөрәкләребез дә, аларныкы да синең кулыңда. Безне җиңүче итәчәк тә син. (Нәвәви, әл-Әзкар: 189).*

## Дошманны тар-мар итү өчен укыла торган дога

Бу доганы Хәзрәти Пәйгамбәр с.г.с. шәхсән үзе укыган:

اللَّهُمَّ مُنْزِلَ الْكِتَابَ سَرِيعَ الْحِسَابِ, اهْزِمِ
الْأَحْزَابَ. اللَّهُمَّ اهْزِمْهُمْ وَ زَلْزِلْهُمْ.

**«Аллаһүммә мүңзиләль-китәәб сәриигъ-әль-хисәәб, иһзимиль-әхзәәб. Аллааһүммәһ-зимһүм үә зәлзилһүм».**

*Әй Коръәнне иңдергән һәм тиз хисап кылучы Аллаһым! Дошманнарны җиңелүгә дучар ит.*

www.darul-kutub.com

*Берләшмәләрен таркат һәм җимер. (Нәвәви, әл-Әзкар: 188).*

## Фәкыйрьлектән котылу өчен дога

Фатыйма (р.а) әтисе Мөхәммәд пәйгамбәр янына барып аннан үзенә хуҗалыкта ярдәм итәчәк  хезмәтче сорады. Аның бу теләгенә җавап итеп Ул (с.) бу доганы укырга тәкъдим итте.

اللَّهُمَّ رَبَّ السَّمَوَاتِ وَ ربَّ الْعِرْشِ الْعَظِيمِ.
رَبَّنَا وَ رَبَّ كُلِّ شَيْءٍ مُنْزِلَ التَّوْرَاةِ وَ الْإِنْجِيلِ
وَ الْقُرْآنِ فَالِقُ الْحَبِّ وَ النَّوَى أَعُوذُ بِكَ مِنْ
كُلِّ شَيْءٍ أَنْتَ آخِذٌ بِنَاصِيَتِهِ. أَنْتَ الْأَوَّلُ فَلَيْسَ
قَبْلَكَ شَيْءٌ وَ أَنْتَ الْآخِرِ فَلَيْسَ بَعْدَكَ شَيْءٌ وَ
أَنْتَ الظَّاهِرُ فَلَيْسَ فَوْقَكَ شَيْءٌ وَ أَنْتَ البَاطِنُ
فَلَيْسَ دُونَكَ شَيْءٌ اقْضِ عَنِّى الدَّيْنَ وَ أَغْنِنِى
مِنَ الْفَقْرِ.

www.darul-kutub.com

**«Аллаһүммә раббәс-сәмәүәтис-сәбги үә раббәль-гәрш иль-гәзыйм. Раббәнәә үә раббә күлли шәй-ин мүңзиләт-тәүрати уәль-инҗиили уәль-куръән. Фәликуль-хәбби уән-нәүәә, әгүүзү бикә миң күлли шәй-ин әңтә әхыйзум бинәәсийәтиһ. Әңтәль-әүүәлү фәләйсә кабләкә шәй-үн үә әңтәль-әхыйр фәләйсә бәгьдәкә шәй-үн үә әңтә-ззааһир фәләйсә фәүкакә шәй-үн үә әңтәль-бәтыйн фәләйсә дүүнәкә шәй-э. Икъдый гәннид-дәйнә үә агънинии минәль-фәкър».**

*«Аллаһым! Әй җиде кат кукләрнең һәм бөек гарешнең Раббысы! Әй безнең һәм һәр әйбернең Раббысы! Әй Тәуратны, Инҗилне һәм Коръәнне иңдергән, орлыкларны һәм төшләрне ачучы Аллаһым! Синең көчен астында? Булган бөтен әйбернең зарарыннан синең затыңа Сыенам. Син Әүүәлсең (Беренче) ки, сина хәтле бернәрсә дә юк. Син Ахир, синнән соң бернәрсә дә юк. Син Захир, синнән өстен берни юк. Син Батын, синең алдыңда берни була алмый. Минем бурычымны түлә һәм мине байыт. (Мөслим: 4/2084).*

## Ачу чыкканда укыла торган дога

Пәйгамбәребез (с.) ачуы чыккан кешегә таһәрәт алуны, басып торса утыруны, утырса ятуны киңәш иткән, ә тагын бер хәдисендә болай диярргә киңәш иткән.

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ.

**«Әгүүзү билләһи минәш-шәйтаанир-раҗиим».**

*«Аллаһның рәхмәтеннән мәңгегә куылган шайтанның начарлыгыннан Аллаһка сыенам». (Мөслим, Бирр: 30).*

## Күк күкрәгәндә, яшен яшьнәгәндә укылачак дога

Бу доганы пәйгамбәребез киңәш иткән:



www.darul-kutub.com

اللَّهُمَّ لاَ تَقْتُلْنَا بِغَضَبِكَ وَ لاَ تُهْلِكْنَا بِعَذَابِكَ وَ
عَافِنَا قَبْلَ ذَلِكَ.

**«Аллаһүммә ләә тәкътүлнәә бигадабикә үә ләә түһликнә би гәзәәбикә үә гәәфинәә каблә зәәликә».**

*«Аллаһым! Ачуың белән үтермә, ачуың белән дә безне һәлак итмә. Моннан соң булачак начар нәтиҗәләрдән (фәлакәт) безне сакла». (Бохари, Әдәбил-муфред: 198).*

## Күз тимәсен өчен дога

Пәйгамбәребез (с.), Хәсән белән Хөсәенгә (Аллаһ алардан риза булсын) күз тимәсен дип мондый дога кылган:

أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللهِ التَّامَّةِ مِنْ كُلِّ شَيْطَانٍ وَ
هَامَّةٍ وَ مِنْ كُلِّ عَيْنٍ لاَمَّةٍ.

**«Әгүүзү бикәлимәәт-илләһит-тәәәммәти миң күлли шәйтаанир үә һәәәммәти үә миң күлли гәйнил ләәәммәһ».**



www.darul-kutub.com

*«Һәр шайтаннан, зарарлы әйберләрдән һәм начар күзләрдән сүзләрнең хөрмәтенә Аллаһка сыенам». (Бохари: 4:119).*

Күз тиюдән бу аятьне уку киңәш ителә:

وَإِنْ يَكَادُ الَّذِينَ كَفَرُوا لَيُزْلِقُونَكَ بِأَبْصَارِهِمْ لَمَّا سَمِعُوا الذِّكْرَ وَيَقُولُونَ إِنَّهُ لَمَجْنُونٌ ۚ * وَمَا هُوَ إِلَّا ذِكْرٌ لِلْعَالَمِينَ .

**«Үә ий йәкәәд-үлләзиинә кәфәруу ләйүзликуунәкә биәбсаариһим ләммәә сәмигүззикра үә йәкуулүүнә иннәһүү ләмәҗнүүн. Үә мәә һүә илләә зикрул лиль-гәәләмиин».**

*«Чынлап та шул кәферләрнең, Коръәнне ишеткән вакытта, сине күзләре белән бәреп егасы килә иде. «Ул, һичшиксез, акылдан язган кеше», - дияләр. Ә бит Коръән бөтен галәмнәр өчен шәфкатьтән башка бер әйбер дә түгелдер». (Каләм, 51-52).*



www.darulkutub.com

## Теләк (хаҗәт) намазы догасы

Бу хөрмәтле Пәйгамбәрнең (с.) өйрәткән догаларыннан берсе:

لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ الْحَلِيمُ الْكَرِيمُ . سُبْحَانَ اللَّهِ رَبِّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ . اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ أَسْأَلُكَ مُوجِبَاتِ رَحْمَتِكَ وَعَزَائِمَ مَغْفِرَتِكَ وَالْغَنِيمَةَ مِنْ كُلِّ بِرٍّ وَالسَّلَامَةَ مِنْ كُلِّ إِثْمٍ. لَا تَدَعْ لِي ذَنْبًا إِلَّا غَفَرْتَهُ وَلَا هَمًّا إِلَّا فَرَّجْتَهُ وَلَا حَاجَةً هِيَ لَكَ رِضًا إِلَّا قَضَيْتَهَا يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

**«Ләәә иләәһә илләллааһуль-хәлиимүль-кәриим. Сүбхәәнәллааһи раббиль-гәршиль-гәзыйм. Әлхәмдү лилләһи раббиль-гәәләмин, әсьәлүкә мүүҗибәәти рахмәтик үә гәзәәимә мәгъфиратик үәль-ганиимәтә миң күлли бир-рин үәс-сәләәмәтә миң күлли исмин. Ләә тәдәгь лии зәнбән илләә гафәртәһү үә ләә һәммән илләә фәрраҗтәһү үә ләә хәәҗәтән һийә ләкә ридан илләә кадайтәһәә йәәә әрхәмәр-раахимиин».**

*Хәлим һәм юмарт булган Аллаһтан башка һичбер илаһ юк. Бөек Гарешнең Раббысы булган Аллаһның кимчелекләре юк. Мактау галәмнәрнең раббысы Аллаһка хас. Синнән, рәхмәтең белән яхшылык бируең аркасында яхшылык сорыйм. Янә дә һәр яктан гафу итүеңне һәм гөнаһтан саклавыңны сорыйм. Миндә гафу ителмәгән бер генә гөнаһымны, бетерелмәгән бер генә борчуымны да калдырма. Әй мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе! Үзең риза булган теләгемне үтә». (Нәвәви, әл-Әзкәр: 167).*

## Авыруны күргәч укыла торган дога

Бу доганы яраткан Пәйгамбәребез (с.) өйрәткән:

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِى عَافَانِى مِمَّا ابْتَلاَكَ بِهِ وَفَضَّلَنِى عَلَى كَثِيرٍ مِمَّنْ خَلَقَ تَفْضِيلاً.

**«Әлхәмдү лилләһилләзии гәәфәәни миммә-бтәләәкә биһи үә фәддаләнии гәләә кәсииримиммән халәка тәфдыйләә».**

*Син тотылган бәладән миңа саулык бир һәм яратылганнарның күпчелегенә мине мәрхәмәтле кылган Аллаһка мактау булсын. (Тирмизи, Дәгъват: 3428).*

## Сугышта Аллаһтан ярдәм сорап укыла торган дога

Бу доганы яраткан Пәйгамбәребез (с.с.) өйрәткән:

اللّٰهُمَّ أَنْتَ عَضُدِى وَ نَصِيرِى. بِكَ أَحُوْلُ وَ بِكَ أَصُولُ وَ بِكَ أُقَاتِلُ.

**«Аллаһүммә әңтә гәдудии үә нәсыйрии. Бикә әхүүлү үә бикә әсуулү үә бикә үкаатилү».**

*Аллаһым! Миңа көчне син, ярдәмне дә бары тик син бирәсең. Бары синең өчен сугышка барам, синең*



www.darul-kutub.com

*өчен һөҗүм итәрмен һәм синең ярдәмең белән сугышырмын. (Нәвәви, әл-Әзкәр: 188).*

## Сугышта дошманны тар-мар итү өчен укыла торган дога

Бу доганы пәйгамбәребез (с.) үзе кылган:

اللَّهُمَّ مُنْزِلَ الْكِتَابِ سَرِيعَ الْحِسَابِ, اهْزِمْ الْأَحْزَابَ. اللَّهُمَّ اهْزِمْهُمْ وَ زَلْزِلْهُمْ.

**«Аллаһүммә мүңзиләль-китәәб, сәриигәль-хисәәб, иһзимиль-әхзәәб. Аллаһүммә-һзимһүм үә зәлзилһүм».**

*«Әй Китапны иңдергән һәм хисапны тиз ясаучы Аллаһым! Дошманнарымны җиңелергә мәҗбүр ит! Аллаһым! Аларны тар-мар ит һәм дерелдәт».*

www.darul-kutub.com

## Авырудан савыгу өчен укыла торган дога

اللَّهُمَّ عَافِنِى فِى جَسَدِى وَ عَافِنِى فِى بَصَرِى وَ اجْعَلْهُ الْوَارِثَ مِنِّى. لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ الْحَلِيبُ الْكَرِيمُ سُبْحَانَ اللهِ رَبِّ الْعَرْشِ العَظِيمِ و الْحَمْدُ للهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ.

**«Аллааһүммә гәәфинии фии җәсәдии үә гәәфинии фии бәсарии үә-җгәльһүль-үәәрисә миннии. Лә иләәһә илләллаһүль-хәлиим үль-кәриим сүбхәәнәллаһи раббиль-гршиль-гә-зыйм үәлхәмдү лилләһи раббиль-гәәләмиин».**

*Аллаһым! Тәнемә тормыш көче, күрүемә дә сыйххәт һәм көч бир. Күрүемне миңа варис кыл. Хәлим һәм юмарт булган Аллаһтан башка илаһ юктыр. Бөек гарешнең раббысы булган Аллаһның җитешсез яклары юк дип шәһадәт китерәм. Шөкер итү галәмнәрнен раббысы булган Аллаһка багышланган булырга тиештер. (Түхвәтүль-әхүәзи: 9/451).*



www.darulkutub.com

## Бер төркемнән курыкканда укыла торган дога

Әбү Бурдә (р.а.) әйтүенчә, пәйгамбәребез берәр төркемнән зыян килмәсен дип бу доганы кыла торган булган:

اللَّهُمَّ إِنَّا نَجْعَلُكَ فِى نُحُورِهِمْ وَ نَعُوذُ بِكَ مِنْ شُرُورِهِمْ .

**«Аллааһүммә иннәә нәҗгәлүкә фи нүхүүриһим үә нәгүзү бикә миң шүрууриһим».**

*«Аллаһым! Сине саклаячак зат итеп кабул итәбез. Аларның начарлыкларыннан сиңа сыенабыз.» (Әбү Дауд: 1537)*

## Җиңелгәч укыла торган дога

Әбү Һурәйрә (р.а.) әйтеп калдырганча, пәйгамбәребез болай дип үгетли:



www.darul-kutub.com

قَدَّرَ اللهُ وَ مَا شَاءَ اللهُ.

**«Каддəраллаһу үə мəə шəə əллаһ».**

*«Аллаһ шулай насыйп итте һəм Ул телəгəнен эшлəр». (Ибн Мəҗə, 79).*

«Көчле мөэмин (Аллаһка ышанган кеше) көчсездəн яхшырак һəм Аллаһ аны күбрəк ярата. Икесендə дə яхшылык бар. Сиңа файда китерə торган əйберлəрне бар көчең белəн казанырга тырыш. Аллаһтан да ярдəм сора һəм файдалы əйберлəр телəүдəн һич туктама. Əгəр ошамаган əйбер белəн очрашсаң: «Мин шуны телəгəн булсам, шуны эшлəгəн булсам, бу хəл минем белəн булмас иде», – димə, чөнки «Шулай-болай булса иде…» – сүзе шайтанның вəсвəсəсенə һəм хəйлəсенə юл ача. Бары болай диеп əйт:

www.darulkutub.com

## Хозыр (г.с.) догасы

بِسْمِ اللهِ مَا شَاءَ اللهُ, لاَ قُوَّة إِلاَّ بِاللهِ. مَا شَاءَ اللهُ كُلَّ نِعْمَةٍ مِنَ اللهِ. مَا شَاءَ اللهُ الْخَيْرُ كُلُّهُ بِيَدِ اللهِ. مَا شَاءَ اللهُ لاَ يَصْرِفُ السُّوءَ إِلاَّ بِاللهِ.

**«Бисмилләһи мәә шәә Аллаһ, ләә куүәтә илләә билләһ. Мәә шәә Аллаһ күллү нигьмәтим минәллаһ. Мәә шәә Аллаһ əль-хайру күллүһү би йәдилләһ. Мәә шәә Аллаһ ләә йәсърифүссүү–ә иллә билләһ».**

*«Аллаһның исеме белән. Аллаһ нәрсә теләсә, шул булыр. Куәт һәм кодрәт Аллаһның бүләге белән. Һәр нигъмәт Аллаһтандыр. Яхшылык бөтенләй Аллаһның идарәсендә. Аллаһ нәрсә теләсә, шул булыр. Начарлыкны бары Аллаһ кире борыр.» (Ихъя, 1/222).*

## Әйүб (г.с.) пәйгамбәрнең авыруына каршы кылган догасы

Әййүб г.с. авырганда болай дип дога кылган:



www.darul-kutub.com

إِنِّى مَسَّنِىَ الضُّرُّ وَ أَنْتَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ.

**«Иннии мәссәниәд-дурру үә әңтә әрхәмүр-рахимиин».**

*«(Раббым!) Бу авыру мине сырып алды. Син исә мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе» (Әнбия: 83)*

## Муса г.с. сөйләм дефекты бетсен өчен кылган догасы

Муса г.с. кылган догалардан берсе. Ул фиргавеннең зарарына каршы, эшенең җиңеләйтелүе өчен һәм тагын күп әйбер өчен доганы болай дип кылган:

